# Мин = милләт

## Асыл

ГӨЛНАЗ ГАТИНА, ТАТАР, 24 ЯШЬ



Милли асыл кешенең **КҮҢЕЛЕННӘН, ТӘРБИЯСЕННӘН** киләдер дип уйлыйм. Бездә бу **ГАИЛӘДӘН** үк башлана. Милләткә, милли традицияләргә, телгә карата мәхәббәт булсын өчен әти-әни күп көч куйды дип саныйм. Әйтик, безнең гаиләдә Татарстан Конституциясе көне дә башка бәйрәмнәр кебек үк билгеләп үтелә. Безнең өчен боларны белмәү оят эш санала.

Көндәлек тормышта мин үземнең татар булуымны дәлилләп, иң элек, татар телендә сөйләшәм. «Башка җиргә күченеп китәргә теләмисеңме?» дигән сорауга да: **«МИНЕМ ТАМЫРЛАРЫМ МОНДА. МИҢА ЧИТТӘ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БАШКА КЫЕН БУЛЫР ИДЕ»**, – дип җавап бирәм. Университетта укыганда да күбрәк татар мохите булган урыннарга йөрергә тырыштым.

Кием-салымда да татарлыкны сакларга тырышам. Изү, беләзек, татар элементы кергән яулык, түштамга, алка, акча янчыгы дисеңме... Коллекциям зур! Бер караганда, бу – кечкенә генә көндәлек нәрсәләр. Әмма аларда да миллилекне күрсәтеп була һәм кирәк. **БИЗӘКЛӘР – УЛ БИТ МАТУРЛЫК КЫНА ТҮГЕЛ, Ә СИМВОЛ, МӘГЪНӘ ДӘ!** Алар аша күңел халәтен дә чагылдырып була.

Мин бик бәхетле! **ТУГАН ТЕЛЕМДӘ БЕЛЕМ АЛУ** мөмкинлеге булды. Физика, химия, биология, математиканы да татар телендә укыдым. **ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУ КЫЕНЛЫК ТУДЫРМАДЫ, КИРЕСЕНЧӘ, МИҢА БУЛЫШТЫ ГЫНА.** Бу – минем өчен «плюс» кына! Мин бөтенләй башка төрле фикерлим.







Безнең өйдә мич тә бар. Без ул мичтә икмәк тә, коймак та пешерәбез. Безнең әти: **«ТАТАР ӨЕНДӘ МИЧ БУЛЫРГА ТИЕШ.** Анда пешкән ризык тәме дә башка», – дип әйтергә ярата.

Милләтне ярату – ул әле **«МИН – ТАТАР!» ДИП КЫЧКЫРЫП ЙӨРҮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ.** Милләткә булган мәхәббәтне эш-гамәлләрең, сөйләмең, киемең, әйләнә-тирәңдәге кешеләр белән күрсәтү дөресрәк.

Туган тел – иң **КАДЕРЛЕ** нәрсә. Иң беренче сүзебезне шул телдә әйтәбез. Телне саклау өчен күпләр көч куйган. Безнең аны югалтырга бернинди **ХАКЫБЫЗ ЮК!** Туган телне саклау өчен без дә үз өлешебезне кертергә тиеш. Татар кызлары аеруча. Күпләр: «Балам татар телендә сөйләшми», – ди. Ата-анасы гаиләдә шул телдә сөйләшә икән, бала да сөйләшәчәк.

Оясында ни күрсә, очканда шул булыр. Милләткә, телгә булган мәхәббәтне балаларыма **ТАПШЫРАЧАКМЫН!** Хатын-кыз тәрбиясеннән күп нәрсә тора.

Милләт белән горурлану өчен **ӨЧ ТӨП СӘБӘП:** бай, тетрәндергеч тарихым; телем һәм миллилекнең замана белән яраклаша алуы.

**МИНЕМ ДӘ МИЛЛӘТЕМ ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ КЕШЕ БУЛАСЫМ КИЛӘ!**





**Гөлназның көндәлек тормышында да миллилеккә урын күп. Алка, калфак, озын толым, изү... Гөлназга карап күпләр: «Чын татар кызы бу!» – дип соклана. Хәер, үзегез дә фотога карап шулай уйлап куйгансыздыр.**

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ.